# КАРАР

2019 елның 26 ноябре № 1

Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 25 ноябрендә һәм 2019 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1. «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 70 яшьтәге һәм өлкәнрәк ялгыз гражданнар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- янгын сүндерү депосының түбәсен ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- Түбән Үрәс авылында янгын гидранты, янгын җиңсәләре сатып алу һәм урнаштыру;
- Түбән Үрәс авылы балалар мәйданчыгына балалар өчен уен һәм спорт җиһазлары сатып алу;
- Түбән Үрәс авылы урам су җыю колонкаларын коймалау (материаллар сатып алу).
- урамнарны яктырту өчен энергия саклый торган лампалар сатып алу;
- Түбән Үрәс авылында артезиан скважиналары өчен тирәннән суырту насосы сатып алу;
- җәйге чорда территорияне чабу өчен бензин чалгысы сатып алу;
- авыл җирлеге авылларында юлларны кардан чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 167 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 93.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 92 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 1 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Түбән Үрәс авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

3. Түбәндәге мәсьәләне: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 70 яшьтәге һәм өлкәнрәк ялгыз гражданнар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- янгын сүндерү депосының түбәсен ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- Түбән Үрәс авылында янгын гидранты, янгын җиңсәләре сатып алу һәм урнаштыру;
- Түбән Үрәс авылы балалар мәйданчыгына балалар өчен уен һәм спорт җиһазлары сатып алу;
- Түбән Үрәс авылы урам су җыю колонкаларын коймалау (материаллар сатып алу).
- урамнарны яктырту өчен энергия саклый торган лампалар сатып алу;
- Түбән Үрәс авылында артезиан скважиналары өчен тирәннән суырту насосы сатып алу;
- җәйге чорда территорияне чабу өчен бензин чалгысы сатып алу;

авыл җирлеге авылларында юлларны кардан чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

4. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы: Р.Х. Шамеев